КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 декабрь г.Казань № 1258

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеген раслау турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче; 2019 ел, 13 июнь, 487 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 748 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 926 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 993 нче; 2020 ел, 11 февраль, 86 нчы; 2020 ел, 9 апрель, 264 нче; 2020 ел, 30 апрель, 353 нче; 2020 ел,

28 сентябрь, 878 нче; 2021 ел, 20 май, 347 нче; 2021 ел, 9 август, 692 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «22. | Салым түләүче физик затның транспорт чарасын мәҗбүри тартып алуга бәйле рәвештә транспорт салымын исәпләүне туктату турындагы гаризасын кабул итү»; |

«Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» бүлекчәсенең 8 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

IV бүлектә:

56 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

58 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 61 һәм 62 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «61. | Уку-укыту һәм практик дәресләр, лекцияләр, тренинглар үткәрү |
| 62. | «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (функцияләре)» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә автомат режимда электрон документ рәвешендә формалаштырылган яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы профилактик прививкалар яки вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре һәм (яки) яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) аркасында авырган авыру турындагы сертификатны кәгазьдә бастырып чыгару буенча хезмәт күрсәтүләр». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин